ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 с.Старое Дрожжаное № 261

Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 10 маендагы 315 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 августындагы 481 номерлы карары (02.02.2018 № 66, 20.01.2023 № 10 редакциясендә) белән расланган Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, II бүлекнең 1 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| «№ п/п | Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Учреждение җитәкчесе | 25 014 |
| 2. | Оператив дежур | 19 242». |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.
3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов